Гөлчәчәк
Гульчечек

Татар халык әкияте
Татарская народная сказка

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2007

УДК 821.512.145-34:398
ББК 82(2Рос=Тат)4 я70
Г97

Рәссамы *Нияз Хаҗиәхмәтов*

Художник *Нияз Хазиахметов*

**Гөлчәчәк:** Татар халык әкияте / Гульчечек: Татарская народная сказка.— Казан: Мәгариф, 2007.— 15 б.: рәс. б-н.
ISBN 978-5-7761-1665-0

ISBN 978-5-7761-1665-0
© «Мәгариф» нәшрияты, 2007
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2007

Йокы алмый…
Безнең батыр әле
Аждаіаны табар юлда гына.
Коткарырга тиеш таң былбылын,—
Алмаз кылыч таккан билбавына…
Таң былбылы — гүзәл бер кыз икән,
Ул — читлектә, убыр оясында.
Ул яшь түгә булыр,
белми әле
Бу батырның юлга чыгасын да…

Борын-борын заманда зур карурман эчендә бер убырлы карчык торган, ди. Аның бер улы белән Гөлчәчәк атлы килене булган. Карчык бик явыз икән, ди. Гомер-гомергә яхшы кешеләрне аздырып, батырларны юлдан яздырып

йөргән. Карчыкның улы, анасының явызлыгына түзә алмыйча, дөнья гизәргә, бәхет эзләргә чыгып киткән.

Гөлчәчәк әниләрен бик сагына икән, тик аны каенанасы — убырлы карчык — бер җиргә дә чыгармый, ди. Үзе төннәрен яхшы кешеләрне аздырырга, батырларны юлдан яздырырга чыгып киткәндә дә киленен өендә бикләп калдыра икән, ди.

Төннәрдән бер төнне убырлы карчык, нindидер явызлык эшләргә чыгып киткәндә, ишеккә йозак салырга оныткан, ди. Көлгә салган күмәчләрен дә калдырып киткән, ди.

Аның чыгып китүе булган, ишекнең ачык калуын белгәч тә, Гөлчәчәк әниләренә китәргә җыена башлаган, ди.

Урман эче бик якты,
Күктә айлар калыкты,
Көлдән күмәч аламын,
Әниләргә барамын,
Әниләргә барамын,—

дип җырлый-җырлый куенына төче күмәч кыстырган да, ди, әниләренә кунакка чыгып киткән, ди.

Төн киткән, көн киткән, ди, бара торгач, байтак җир киткән. Ул арада убырлы карчык кире әйләнеп кайткан да килене артыннан куа чыккан. Соры Бүре төсенә кергән дә, ди, җирне исни-исни чабып киткән, ди, чаба торгач, киленен куып җиткән, ди. Гөлчәчәкнең каршысына төшкән дә, ди, калын тавыш белән улап җибәргән, ди:

Көлтә-көлтә койрыгым
Болгый-болгый улаем,
Күмәчләремне бирмәсәң,
Калҗа-калҗа тураем,
Калҗа-калҗа тураем.

Гөлчәчәк бик курыккан, күмәч биреп кенә котылыр иде дә, ул вакытта инде аның күмәче калмаган. Ары каранган, ди, бире каранган, ди, якында гына тузгак башлы, куыш

эчле бер карама күргән, ди. Шул карамага ялына башлаган, ди:

Әйләнмәле карама,
Бәйләнмәле карама,
Соры Бүре куып җитте,
Яшерсәнә, карама,
Яшерсәнә, карама.

Әйләнмәле карама Гөлчәчәкне бик кызганган, ди. Тиеннәр чикләвек җыеп, ярканатлар көн уздырып чыга торган кечкенә куышының ишеген ачып җибәргән икән, Гөлчәчәк куышка кергән дә качкан, ди.

Соры Бүре карама төбен тырный-тырный улаган да, ди,

Гөлчәчәкне чыгара алмагач, таң алдыннан өенә кайтып киткән, ди.

Ул арада таң аткан, кояш чыккан, көн булган. Гөлчәчәк, карамага рәхмәт әйтеп, тагын үз юлына чыгып киткән.

Бара торгач, кич булган. Соры Бүре, килененең эзеннән исни барып, тагын куып җиткән. Гөлчәчәкнең алдына төшеп, тагын улап җибәргән, ди:

Көлтә-көлтә койрыгым
Болгый-болгый улаем,
Күмәчләремне бирмәсәң,
Калҗа-калҗа тураем,
Калҗа-калҗа тураем.

Гөлчәчәк бик курыккан, ди. Ары каранган, ди, бире каранган, ди. Түгәрәк аланда бик матур бер күл бар икән. Гөлчәчәк шул күлгә ялына башлаган, ди:

Түгәрәк алан, көмеш күл,
Көмеш күлнең суы мул.
Соры Бүре куып җитте,
Яшерсәнә, көмеш күл,
Яшерсәнә, көмеш күл!

Көмеш күл Гөлчәчәкне бик кызганган, ди, тирән суын айкалдырып, дулкыннарын чайкалдырып, Гөлчәчәк басып

торган җирне тирән су белән урап алган, Соры Бүре күл читендә бүленеп калган, ди.

Соры Бүре күл читен тырный-тырный төн буе улаган да, Гөлчәчәк янына керә алмагач, таң алдыннан тагын өенә кайтып киткән, ди.

Ул арада таң аткан, кояш чыккан, көн булган. Гөлчәчәк, көмеш күлгә рәхмәт әйтеп, тагын үз юлына чыгып киткән. Барган, ди, барган, ди, иртә киткән, кич киткән, китә торгач, урманның кырыена ук чыгып җиткән. Инде әниләренең өй түбәләре дә күренә башлаган, ди. Тик шул урында Соры Бүре тагын куып җиткән, ди. Бу юлы инде бигрәк тә каты ачуланып, улап җибәргән, ди:

Көлтә-көлтә койрыгым
Болгый-болгый улаем,
Күмәчеңне ашатмасаң,
Калҗа-калҗа тураем,
Калҗа-калҗа тураем.

Гөлчәчәк бик курыккан. Ары каранган, бире каранган да басу кырыенда үсеп утырган кушкаенга менеп киткән, ди. Соры Бүре кушкаенның тамырларын казый башлаган, ди.

Гөлчәчәк бик курка икән, ди.

— Инде монда кайтып җиткәч тә әниләрне күрмичә үләрмен микәнни соң? — дип әйтеп, бик елап утыра икән, шунда кушкаен башына бер сыерчык килеп кунган, ди. Гөлчәчәк сыерчыкка ялына башлаган:

Ала муен сыерчык,
Кола муен сыерчык,
Чәч бөртегем — әманәтем,
Илтеп бирче, сыерчык,
Илтеп бирче, сыерчык.

Гөлчәчәк сыерчыкка бер-ике чәч бөртеген алып биргән, ди. Сыерчык аны алып Гөлчәчәкләрнең әниләренә очып киткән дә, ди, чәч бөртеген аларның капкаларына элеп куйган, ди.

Гөлчәчәкнең абыйсы капка төбенә чыккан икән, чәч бөртекләрен күргән.

— Әіә, кара юргам кашынып торганда ял бөртекләре калган икән,— дип әйтеп, чәч бөртеген алып кереп думбрага кыл итеп тарткан, ди.

Гөлчәчәкнең җиңгәсе думбраны аяк тибеп бии-бии уйный башлаган икән, думбра кылы Гөлчәчәк булып җырлап җибәргән:

Бии-бии уйнама,
Билгенәем авырта.
Тибә-тибә уйнама,
Түбәләрем авырта...

Моңар җиңгәсенең исе киткән:

— Әбәү, бу думбрага ни булган? — дип әйтеп, думбраны иренә биргән. Ире чиртеп-чиртеп уйный башлаган икән, думбра тагын җырларга тотынган:

Басма-басма, абыем,
Башкынаем авырта.
Чиртмә-чиртмә, абыем,
Чәчкенәем авырта.
Урман буе кушкаен,
Кушкаенда сеңлең бар.
Кушкаенның төбендә
Каенанам — убыр бар.
Думбраңны куй, абый,
Кушкаенга кил, абый!

Шуннан соң абыйсы:

— Карасана, Гөлчәчәк сеңлем харап була язган бит,— дип чукмарын алган да, ди, бүре тибә торган атына атланып, урман буена чапкан, ди. Ул барып җиткәндә, Соры Бүре кушкаенның тамырларын актарып бетерә язган иде, ди. Кушкаен, менә авам, менә авам, дип кенә торадыр иде, ди.

Гөлчәчәкнең абыйсы Соры Бүрене бәреп үтергән дә, ди, Гөлчәчәкне өйләренә алып кайткан, ди.

Шуннан бирле Гөлчәчәк бик әйбәт гомер итә башлаган, ди.

Бүген барып, кичә кайттым, мин дә булдым аларда. Сыйхөрмәт бик дан булды, ашатканнары май, эчерткәннәре бал булды. Ике мичкә, бер чүмеч, теләсәң күпме эч. Тик авызга эләкми, мыек кына чылана.

В давние времена жила в дремучем лесу колдунья, и были у неё сын и сноха по имени

Гульчечек. Колдунья была злая-презлая. Многих батыров она с пути сбила, многих людей она в трясину заманила... Не вынес сын всего этого и ушёл скитаться по свету, ушёл счастья искать.

А Гульчечек грустила-тосковала по матери с отцом, но старуха свекровь никуда её не отпускала, держала взаперти.

Однажды ночью, отправляясь, как обычно, по нечистым делам своим, колдунья забыла закрыть дверь на замок. И хлеб в печи оставила.

Только она ушла, Гульчечек стала собираться к родителям.

Лес дремучий видит сны,
Звёзды блещут среди тьмы.
Хлеб из печки выну я,
В путь далёкий выйду я,
Навещу своих родных...—

тихо напевала она и, вынув из печи тёплый душистый хлеб, сунула его в котомку, и выбежала из избушки.

Минула ночь, минул день. Далеко успела уйти Гульчечек. Тем временем колдунья вернулась и, не найдя сноху дома, кинулась за ней в погоню. Превратилась она в Серого Волка и бежит, принюхиваясь, по следу. И вот уже настиг Серый Волк беглянку, и воет страшным голосом:

Я волчище — серый хвостище,
Страшный у меня голосище.
Если хлеб не отдашь мне и спрячешь,
Так и знай: у меня ты поплачешь,
Ох, поплачешь...

Испугалась Гульчечек. Отдала бы она хлеб, чтоб спастись, да уже ни крошки не осталось от него. Стала она растерянно озираться по сторонам, увидала поблизости большой, раскидистый, дуплистый вяз и взмолилась:

О густой тенистый вяз,
О приветливый мой вяз!
Серый Волк бежит за мной.
Помоги же мне, укрой
Ты зелёною листвой!

Пожалел вяз Гульчечек, развернулся к ней уютным дуплом, где днём скрывались летучие мыши и куда белки складывали орешки, и беглянка в нём спряталась.

Серый Волк всю ночь выл под вязом и царапал когтями землю, а под утро ни с чем убежал домой.

Занялась заря, взошло ясно солнышко, наступил день. Гульчечек поблагодарила доброе дерево и отправилась дальше. Шла она, шла... и стало вечереть. Серый Волк вскоре опять по следу настиг сноху и завыл жутким голосом:

Я волчище — серый хвостище,
Страшный у меня голосище.
Если хлеб не отдашь мне и спрячешь,
Так и знай: у меня ты поплачешь,
Ох, поплачешь...

Испугалась бедная Гульчечек. Смотрит растерянно по сторонам и видит: посреди зелёного луга блестит красивое серебряное озеро. Взмолилась она:

О озёрная вода!
Приключилась беда.
Серый Волк бежит за мной.
Помоги же мне, укрой
Ты серебряной волной!

Серебряное озеро пожалело Гульчечек, раскачало глубокие воды свои, вздыбило волны, и беглянка очутилась

на маленьком островке, окружённом со всех сторон водой. Серый Волк остался на берегу. Всю ночь выл он у озера, царапал когтями землю, наутро же убежал ни с чем домой.

Занялась заря, взошло ясно солнышко, наступил день. Гульчечек поблагодарила доброе озеро и снова отправилась в путь. Шла она, шла... и опять сумерки стали сгущаться. А уже и лес кончается, и крыша дома родительского видна. Но Серый Волк и на этот раз настиг беглянку по следу и завыл:

Я волчище — серый хвостище,
Страшный у меня голосище.
Если хлеб не отдашь мне и спрячешь,
Так и знай: у меня ты поплачешь,
Ох, поплачешь...

Испугалась Гульчечек. Смотрит по сторонам, увидела одинокую берёзу и забралась на неё. А Серый Волк роет когтями землю под берёзой, к корням подбирается.

Дрожит Гульчечек от страха и плачет:

— Неужели так и умру здесь, совсем близко от дома родного, не повидав мать с отцом...

Тут на ветку берёзы сел скворец. Гульчечек взмолилась:

Ласковый мой скворушка,
Певчий друг мой скворушка!
Ты лети за луг-лужок,
Передай мой волосок,
Передай мой волосок!

Гульчечек дала в клюв скворушке волосок, и тот полетел прямо к дому, где жили её родители. Оставил волос на воротах и улетел.

Той порой вышел к воротам брат, заметил волос и взял его.

— Не иначе как из гривы моего вороного коня,—подумал он и натянул дома волос на домбру.

Жена взяла домбру в руки и стала, притопывая, играть на ней. Вдруг струна на домбре запела голосом Гульчечек:

Не играй, ой, не играй,
Ломит руки, ноги.
Не пляши, ой, не пляши,
Приди на подмогу!..

Удивилась женщина:

— О Аллах, что это с домброй случилось? — и передала её мужу. Тот потрогал было струны, и опять домбра запела:

Не играй, брат, не играй,
Поясница, ох, болит.
Брат, струну не задевай,
Голова моя болит.
У опушки на берёзе
Льёт твоя сестрица слёзы.
А свекровь — колдунья злая —
Волком воет, не пускает.
Брат, домбру ты отложи
И на помощь поспеши!..

Тут брат всё понял:

— Сестрёнка Гульчечек в беду попала! — вскочил он с места, взял дубину, оседлал ретивого коня и поскакал к лесу. Подоспел он в самый раз: Серый Волк вырыл под берёзой огромную яму, и дерево уже готово было повалиться...

Убил он Серого Волка, а сестру привёз домой.

С тех пор Гульчечек зажила счастливо, не ведая ни горя, ни печали.

И я у них бывал: сегодня пришёл, а вчера ушёл. Угощали меня там на славу: масло ел да мёд пил. Две бочки, один ковш — знай пей сколько хочешь. Жаль одно: по усам текло, а в рот не попало.

Литературно-художественное издание

Для младшего школьного возраста

# Гульчечек

Татарская народная сказка

Перевод *Р. Кожевниковой*

Казань. Издательство «Магариф». 2007

*На татарском и русском языках*

Әдәби-нәфис басма
Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

# Гөлчәчәк

Татар халык әкияте

Редакторы *Л. Ә. Гыйззәтуллина*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Л. И. Матвеева*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.03.07. Форматы 60ә90$^{1}/_{8}$. Офсет кәгазе №1. «Журнальная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 2,0. Нәшер-хисап табагы 1,07. Тиражы 2000 д. Заказ К 7/68.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.